| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2024 г.Казань № 313-1/э-2024

2025 елга «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел – Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционер җәмгыяте арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә индивидуаль тарифлар билгеләү турында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2024 елның 13 ноябрендәге 25-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2025 елга календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2025 елга «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел – Нократ» филиалының кирәкле тулай керемен (югалтуларны түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.11.2024 № 313-1/э-2024
карарына 1 нчы кушымта

2025 елның 1 гыйнварыннан башлап 2025 елның 31 декабренә кадәр
«Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Волго-Вятский» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2025 | 1 193 831,32 | 208,28 | 2,98418 | 1 193 831,32 | 208,28 | 2,98418 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.11.2024 № 313-1/э-2024
карарына 2 нче кушымта

«Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ»
филиалы филиалының 2025 елга кирәкле тулай кереме
(югалтуларны түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының исеме | Ел | Югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы | 2025 | 52 991,78 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге